**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

12.09.2022 797-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 19 июнендәге 502-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 19 июнендәге 502-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын, җирле һәм төбәк әһәмиятендәге, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, радиоактив калдыкларны, җитештерү һәм кулланудагы I-V класс куркынычлылык калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклый торган урыннардан тыш, җирле әһәмияттәге җир

асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшкәртмәләрен, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле булган бораулау скважиналарын һәм башка төр корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып җир асты байлыкларыннан файдаланучылар – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затлар, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгән Россия Федерациясе гражданнары булган шәхси эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.»;

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков